Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Түбән Наратбаш авылында гражданнар җыены карары

15 декабрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Түбән Наратбаш авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2022 елда Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Түбән Наратбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Түбән Наратбаш авылы юлларын ремонтлауга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Түбән Наратбаш авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы _________ И.И. Галиуллин

Халык җыены секретаре _________ Г.Н. Абзалова